Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«12» ноябрь 2020 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пункты территориясендә торучы, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Кәкре Атау торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Кәкре Атау торак пунктында янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Кәкре Атау торак пунктында парк территориясен киртәләп алу өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтү.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева